**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Мэсгут авыл җирлеге Советы карары**

ав. Мэсгут №42 2017 елның 20 марта

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Мэсгут авыл җирлеге территориясендә
гражданнарның үзара салымы турында һәм гражданнарның
үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе хакында
13.05. 2014 № 34 нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы нигезендә

Мэсгут авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мэсгут авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы турында һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе хакында 13.05.2014 № 34 нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 3.1 пунктта «агымда» сүзләрен «агымда» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 4.2 пунктта «саны Җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан арта алмый торган һәм алар өчен түләүләр күләме киметелергә мөмкин булган. Күрсәтелгән категориядәге гражданнар җирле референдумда кабул ителгән карар белән билгеләнә.» сүзләрен өстәргә;

1.3. 5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү җирле референдумда кабул ителгән тиешле карар халыкка җиткерелгәннән соң ике ай эчендә Җирлек Башкарма комитетының банк реквизитларын үз эченә алган хәбәр итү нигезендә, шулай ук түләү тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә башкарыла. "

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo. tatarstan.ru. һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo. tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мэсгут авыл җирлегенең законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис: Э.А.Габдрахманов